ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.11 2024 ЕЛ Болгар ш. № 658

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәрендә «Колосок» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә мәктәпкәчә төркемне ябу турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 02 июлендәге 546 номерлы карары белән җитәкчелек итеп, мәктәпкәчә яшьтәге балалар саны кимүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәрендә «Колосок» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә мәктәпкәчә төркемне 2025 елның 1 февраленнән ябарга.

2. «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МУ башлыгы Ермилинга А.Н. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәрендә «Колосок» балалар бакчасы» МББМУ төркемен ябу буенча оештыру-штат чараларын үткәрүне тәэмин итәргә:

2.1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәрендәге «Колосок» балалар бакчасы» МБББМУ тәрбияләнүчеләренең хокукларын саклауны тәэмин итәргә, ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризалары нигезендә, аларның фикерен исәпкә алып, балалар бакчасының ябык мәктәпкәчә төркемендә тәрбияләнүчеләрне, буш урыннар булганда, муниципаль районның башка мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына күчерергә;

2.2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәрендә «Колосок» балалар бакчасы» МБББМУ расланган штат расписаниеләренә нормативлар нигезендә үзгәрешләр кертергә.

3. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының финанс-бюджет палатасына, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль учреждениесенә әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru һәм хокук мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Е. В. Савиновка йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе вазифаларын башкаручы Савинов Е.В.